КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 август г.Казань № 939

2024 – 2026 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт милкенә караган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану өчен муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләмен исәпләп чыгару өчен 2024 – 2026 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын 12,76 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « 2023 – 2025 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында» 2022 ел, 1 август, 741 нче карары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин